ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАРАТЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРАТЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.09.2022. № 14

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 нче елның 12 маенда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеген раслау турында»гы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 12.05.2022 ел, №5 карарына (алга таба – Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 12.05.2022 ел, №5 карары) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 1 пункты Наратлы карарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күмү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964 сум 68 тиенгә әлеге карарның 1 һәм 2 нче кушымталары нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.».

1.2. Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге Башкарма комитетының 12.05.2022 №5 карарының 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Бөгелмә муниципаль районы Наратлы авыл җирлеге Башкарма комитетының Наратлы карарын 2 нче номерлы яңа кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Наратлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә һәм бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

.

**Җитәкче** **С.А. Дмитриев**

13.09.2022 елның 14 номерлы
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
«Наратлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башкарма комитеты
карарының 1 номерлы кушымтасы

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Наратлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә күмү хезмәтенең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (табутта күмү)**

| *№* | *Хезмәтләрнең исеме* | *Хезмәт күрсәтү бәясе, (сум)* |
|---|---|---|
| 1 | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2 | Табутны һәм күмү өчен кирәк булган башка әйберләрне бирү һәм җибәрү | 2271,68 |
| 3 | Зиратка үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) илтү | 988,00 |
| 4 | Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3705,00 |
| БАРЛЫГЫ: | | 6964,68 |

13.09.2022 елның 14 номерлы
Татарстан Республикасы
Бөгелмә муниципаль районы
«Наратлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башкарма комитеты
карарының 2 номерлы кушымтасы

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Наратлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә күмү хезмәтенең гарантияле исемлеге нигезендә (төреп күмү) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе**

| *Хезмәтнең исеме* | *Хезмәт күрсәтү бәясе, сум.* |
|---|---|
| Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| Мәетне (киендерү) төрү | 1348,50 |
| Күмү өчен кирәкле әйберләр белән тәэмин итү һәм җибәрү | 612,44 |
| Зиратка вафат булган кешенең гәүдәсен (калдыкларын) илтү (3,00 сәгать исәбеннән) | 1 560,96 |
| Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3442,78 |
| Барлыгы: | 6 964,68 |